# ТАТАРСТАННЫҢ ТӨЗЕЛЕШ ТАРМАГЫНА – 100 ЕЛ

***ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ ЧОРЫННАН БЕЗНЕҢ КӨННӘРГӘ КАДӘР***

Ерак 1921 елда Идел буена коточкыч корылык килә. Түбән һәм Урта Идел районнарындагы хәлләр бик тә авыр булган. Миллионнарча халык яшәү белән үлем арасында кала. Тик кешеләр шул авыр вакытта да киләчәк турында уйланганнар.

Гражданнар сугышыннан соң Татарстан халык хуҗалыгы советы алдында сәнәгать предприятиеләрен, торак, җәмәгать биналарын һәм корылмаларын торгызу һәм реконструкцияләү мәсьәләсе кискен калкып чыга. Ул вакытта дәүләт төзелеш оешмалары булмаган. Совет хөкүмәтенә шәхси ярдәмчеләрдән файдаланырга туры килә.

Һәм 1921 елның 22 октябрендә Татарстан АССР Беренче Дәүләт универсаль төзелеш конторасы оештырыла. Нәкъ менә шушы дата республиканың төзелеш тармагының туган көне булып санала.

Узган 100 ел эчендә Татарстанның йөзе танымаслык булып үзгәрде. Беркатлы провинциядән республика эре сәнәгать, мәгариф, фәнни һәм мәдәни үзәккә әверелде. ТАССР хезмәтчәннәре фашистлар Германиясен


җиңү эшенә үз өлешләрен кертте, республикада чын-чынлап мобиль хәрби икътисад булдырылды.

1950 – 1980 елларда яңа шәһәрләр һәм тулы бер тармаклар барлыкка килә, йөзләрчә производстволар үсеш ала, шул исәптән энергетика, автомобиль, химия, нефть эшкәртү сәнәгате алга китә. Бу елларда бөтен республика зур төзелеш мәйданчыгына әверелә.

Бөтенсоюз удар комсомол төзелешләре – Казан химия заводы («Казаноргсинтез» ГАҖ), Түбән Кама нефть химиясе комбинаты («Нижнекамскнефтехим» ГАҖ), Кама автомобиль заводы («КАМАЗ» ГАҖ) – аларны торгызу өчен бөтен Советлар Союзыннан комсомолчылар Татарстан төзүчеләренә ярдәм итү өчен килә.

Композитор Александра Пахмутованың Түбән Кама белән танышкач язылган «Смелость города берёт» җырында мондый юллар бар: «Безне сәер кешеләр дип атамагыз, картаймый торган шәһәрләргә беренче таш салган картларны кем дә булса искә төшерер әле». Һәм алар картаймый да. Бу шәһәрләр үсә, яңа производстволар һәм торак кварталлар белән тулылана.

2005 елда 1000 еллыгын билгеләп үткән борынгы Казан да яңара, инфраструктурасы үсә бара. XXI гасырда Россиянең өченче башкаласы һәм төрле милләт, дин кешеләре өчен уртак йорт булган шәһәрнең яңа истәлекле урыннары һәм символлары барлыкка килә.



Татарстанның иң яшь шәһәре – Иннополиска 2012 елның 9 июнендә нигез салынды. Казанның иярчен шәһәре советтан соңгы Россиянең нульдән башлап төзелгән азсанлы шәһәрләренең берсе. Иннополис (Мәскәү янындагы Сколково һәм Новосибирск Кольцово үзәге белән беррәттән) Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләрен үстерү өчен булдырылган өч фән шәһәренең берсе булды.

